# КАРАР

“ 08 ”ноябрь 2021 ел № 1

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Сеҗе авыл җирлеге Иске Му авылында халык җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1,56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2021 елның 08 ноябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча үткәрелгән халык җыены нәтиҗәсе белән халык җыены беркетмәсе тәзелде:

«Сез 2022 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Сеҗе авыл җирлеге Иске Му авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, түләү күләме 100 сум тәшкил иткән көндезге формада укучы студентлардан, 1нче группа инвалидлардан һәм 80 яшьтән узган гражданнардан тыш, 200 сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

- урам утлары челтәрен ремонтлау, шул исәптән яктырткычлар, лампалар, счетчиклар, автоматлар, җибәргечләр (кирәк булганда) сатып алу һәм урнаштыру;

-9 Май урамында 6 нчы йорттан чишмәгә кадәр автомобиль юлын тигезләү өчен вак таш җәю;

- МТЗ 82.1 тракторына асылмалы җиһазлар сатып алуны финанслашу (борылышлы гидравлик отвал, үзбушаткыч тагылма, чапкыч, фронталь эленмәле төягеч сәнәге, чүмечле фронталь эленмәле төягеч);

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен җибәрергә рөхсәт итәргә.

« ӘЙЕ» “КАРШЫ“

Халык җыены беркетмәсе (йомгаклау беркетмәсе) нигезендә сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 94 кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 54 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучылар тавышы түбәндәгечә бүленде:

"Әйе" позициясе өчен халык җыенында катнашкан 52 кеше тавыш бирде; “Каршы" позициясе өчен җыенда катнашкан 2 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Сеҗе авыл җирлегендә Иске Му авылы халык җыенын узган һәм аның нәтиҗәләре дөрес дип танырга.

2.«Сез 2022 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Сеҗе авыл җирлеге Иске Му авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, түләү күләме 100 сум тәшкил иткән көндезге формада укучы студентлардан, 1нче группа инвалидлардан һәм 80 яшьтән узган гражданнардан тыш ,200 сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

- урам утлары челтәрен ремонтлау, шул исәптән яктырткычлар, лампалар, счетчиклар, автоматлар, җибәргечләр (кирәк булганда) сатып алу һәм урнаштыру;

-9 Май урамында 6 нчы йорттан чишмәгә кадәр автомобиль юлын тигезләү өчен вак таш җәю;

- МТЗ 82.1 тракторына асылмалы җиһазлар сатып алуны финанслашу (борылышлы гидравлик отвал, үзбушаткыч тагылма, чапкыч, фронталь эленмәле төягеч сәнәге, чүмечле фронталь эленмәле төягеч);

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен җибәрергә рөхсәт итәргә.

« ӘЙЕ»　　　　　　　　　“КАРШЫ“

мәсьәләсе буенча карар кабул ителгән дип танырга.

3. Әлеге карарны халык күп җыела торган урыннарда мәгълүмат стендларына ТР, Арча районы, Иске Му авылы, Кооперативная урамы, 5А , йорт адресы буенча, интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Арча муниципаль районының рәсми сайтында http://arsk.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы Рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Сеҗе авыл җирлеге башлыгы　　　　　　Р.В.Хәмидуллин